**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменения в структуру Министерства здравоохранения Республики Татарстан

В целях совершенствования деятельности Министерства здравоохранения Республики Татарстан **постановляю**:

1. Внести в структуру Министерства здравоохранения Республики Татарстан, одобренную Указом Президента Республики Татарстан от 26 декабря 2007 года № УП-699 «Вопросы Министерства здравоохранения Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 14 декабря 2011 года № УП-809, от 4 августа 2012 года № УП-641 и от 29 июля 2015 года № УП-681), изменение, изложив ее в новой прилагаемой редакции.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан:
привести свои акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения, обеспечивающие его реализацию;
в 30-дневный срок внести предложения по приведению актов Президента Республики Татарстан в соответствие с настоящим Указом.

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Исполняющий обязанности**
**Президента Республики Татарстан** **А.В. Песошин**

Казань, Кремль
02 ноября 2019 года
№ УП-666

Приложение
к Указу Президента
Республики Татарстан
от «02» ноября 2019 года
№ УП-666

# Структура
# Министерства здравоохранения Республики Татарстан

**Министр**

- Управление делами
  - общий отдел
  - сектор по работе с письмами и обращениями граждан
- Помощник
- Отдел кадров
- Пресс-секретарь
- Второй отдел
- Юридический отдел

**Первый заместитель министра**

- Управление лечебной и профилактической помощи
  - отдел лечебной помощи
  - отдел организации медицинской помощи детям и службы родовспоможения
  - отдел профилактической помощи и здравостроительства
- Отдел организации высокотехнологичной медицинской помощи
- Территориальные управления в городах Набережные Челны, Альметьевске и Нижнекамске

**Заместитель министра – начальник Управления здравоохранения по городу Казани**

- Управление здравоохранения по городу Казани

**Заместитель министра**

- Управление экономического анализа и прогнозирования
  - отдел экономического анализа по средствам бюджета
  - отдел экономического анализа по средствам обязательного медицинского страхования
  - отдел расчета программы государственных гарантий
- Отдел разработки и реализации специальных программ и проектов
- Сектор внебюджетного здравоохранения

**Заместитель министра**

- Управление контроля стандартов и качества медицинской деятельности
  - отдел ведомственного контроля качества медицинской деятельности и медицинских экспертиз
  - отдел внедрения и мониторинга стандартов
  - отдел медицинского образования и аттестации
- Отдел информационных и инновационных технологий
- Сектор защиты информации

**Заместитель министра**

- Управление по фармации
  - отдел управления лекарственным обеспечением
  - отдел регулирования в сфере обращения лекарственных средств
  - отдел регулирования государственного заказа
- Отдел медицинской техники
- Сектор мониторинга и анализа ресурсного обеспечения здравоохранения

**Заместитель министра**

- Управление по лицензированию
  - отдел по лицензированию медицинской деятельности
  - отдел по лицензированию фармацевтической деятельности и деятельности по обороту наркотических средств, психотропных веществ и их прекурсоров, по культивированию наркосодержащих растений
- Сектор координации и контроля деятельности подведомственных учреждений
- Сектор развития первичного здравоохранения

| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

# Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы структурасына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 26 декабрендәге ПУ-699 номерлы Указы нигезендә хупланган (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 14 декабрендәге ПУ-809 номерлы, 2012 елның 4 августындагы ПУ-641 номерлы һәм 2015 елның 29 июлендәге ПУ-681 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы структурасына, аны кушымтада бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә;

30 көн эчендә Татарстан Республикасы Президенты актларын әлеге Указга туры китерү буенча тәкъдимнәр кертергә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын башкаручы** — **А.В. Песошин**

Казан, Кремль
2019 ел, 02 ноябрь
№ ПУ-666

Татарстан Республикасы
Президентының
2019 елның «02» ноябрендәге
ПУ- 666 номерлы Указына
кушымта

# Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы структурасы

**Министр**

- Эшләр идарәсе
  - гомуми бүлек
  - гражданнар хатлары һәм мөрәҗәгатьләре белән эшләү секторы
- Ярдәмче
- Кадрлар бүлеге
- Матбугат секретаре
- Икенче бүлек
- Юридик бүлек

**Министрның беренче урынбасары**

- Дәвалау һәм профилактика ярдәме идарәсе
  - дәвалау ярдәме бүлеге
  - балаларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру һәм бала тудыруда һәм тудыргач ярдәм итү хезмәте бүлеге
  - профилактика ярдәме һәм сәламәтлекне ныгыту бүлеге
- Югары технологияле медицина ярдәмен оештыру бүлеге
- Чаллы, Әлмәт һәм Түбән Кама шәһәрләрендәге территориаль идарәләр

**Министр урынбасары – Казан шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы**

- Казан шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсе

**Министр урынбасары**

- Икътисадый анализ һәм фаразлау идарәсе
  - бюджет акчалары буенча икътисадый анализ бүлеге
  - мәҗбүри медицина иминиятләштерүе чаралары буенча икътисадый анализ бүлеге
  - дәүләт гарантияләре программасын исәпләү бүлеге
- Махсус программалар һәм проектлар эшләү һәм гамәлгә ашыру бүлеге
- Бюджеттан тыш сәламәтлек саклау секторы

**Министр урынбасары**

- Медицина эшчәнлеге стандартларын һәм сыйфатын контрольдә тоту идарәсе
  - медицина эшчәнлеген һәм медицина экспертизалары сыйфатын ведомство контролендә тоту бүлеге
  - стандартларны кертү һәм мониторинглау бүлеге
  - медицина белеме бирү һәм аттестацияләү бүлеге
- Мәгълүмати һәм инновацион технологияләр бүлеге
- Мәгълүматны саклау секторы

**Министр урынбасары**

- Фармация идарәсе
  - дарулар белән тәэмин итүгә идарә бүлеге
  - дарулар әйләнеше өлкәсендә җайга салу бүлеге
  - дәүләт заказын җайга салу бүлеге
- Медицина техникасы бүлеге
- Мониторинглау һәм сәламәтлек саклауны ресурслар белән тәэмин итүне анализлау секторы

**Министр урынбасары**

- Лицензияләү идарәсе
  - медицина эшчәнлеген лицензияләү бүлеге
  - фармация эшчәнлеге һәм наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм прекурсорлары әйләнеше буенча, составында наркотик матдәләр булган үсемлекләр үстерү белән бәйле эшчәнлекләрне лицензияләү бүлеге
- Ведомство карамагындагы учреждениеләр эшчәнлеген координацияләү һәм контрольдә тоту секторы
- Сәламәтлек саклауның беренчел буынын үстерү секторы

___________